КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 апрель г.Казань № 255

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш кирәк-яракларының һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш кирәк-яракларының һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 ел, 15 ноябрь, 832 нче; 2002 ел, 25 октябрь, 625 нче; 2003 ел, 4 апрель, 179 нчы; 2004 ел, 17 май, 239 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 724 нче; 2010 ел, 17 август, 661 нче; 2012 ел, 25 сентябрь, 800 нче; 2016 ел, 31 март, 192 нче һәм 2016 ел, 13 сентябрь, 638 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «һәм шартлаткыч матдәләрнең» сүзләрен «, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә Законсыз саклануча яки табылган коралны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмә нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә законсыз

сакланучы яки табылган коралны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештырырга тәкъдим итәргә.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Законсыз сакланучы яки табылган коралны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмә (теркәлгән).»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда коралны, утлы коралның төп өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне алу чыгымнарын каплау өчен акча карарга.»;

түбәндәге эчтәлекле 4 – 5 пунктлар өстәргә:

«4. Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә массакүләм мәгълүмат чаралары аша законсыз сакланучы яки табылган коралны, утлы коралның төп өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшыру кирәклеге турында аңлату эшен үткәрергә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Законсыз сакланучы яки табылган коралны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмә нигезендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координацияләү органнары эшен оештырырга тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган законсыз сакланган Законсыз сакланучы яки табылган коралны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 1 апрель, 255 нче
карарына кушымта

Законсыз сакланучы яки табылган коралны, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмә

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш кирәк-яракларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү эшен камилләштерү максатларында расланды.

1. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен:

корал, сугыш-кирәк яраклары һәм коралга патроннарга карата «Корал турында» 1996 елның 13 декабрендәге 150-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән төп төшенчәләр кулланыла;

шартлату җайланмалары дигәндә шартлаткыч матдәне һәм шартлауны башлап җибәрү өчен җайланманы функциональ берләштерә торган сәнәгать яки кулдан ясалган әйберләр (запал, шартлаткыч, детонатор һәм ш.б.) аңларга кирәк;

шартлаткыч матдәләр дигәндә тышкы йогынты ясауның билгеле бер төрләре булганда, җылылык һәм газлар барлыкка китерә торган химик әверелдерүгә сәләтле матдәләр аңларга кирәк;

кулдан ясалган утлы корал һәм аның төп өлешләре дигәндә нинди дә булса бүтән предметларны (мәсәлән, ракетницалар, пневматик, старт һәм төзелеш-монтаж пистолетларын, көнкүреш билгеләнешендәге предметларны яки спорт инвентарьларын) үзгәртеп кору юлы белән барлыкка килгән коралны аңларга кирәк, шуның нәтиҗәсендә алар утлы коралның үзлекләрен алалар;

үзгәртеп эшләнгән корал дигәндә аларның тактик-техник характеристикалары һәм үзлекләренең билгеләнгән тәртибен бозып үзгәртүне аңларга кирәк (мәсәлән, башка предметларны имитацияләү өчен аларның формасын үзгәртү, шома көпшәле ату коралы көүсәсен сырлы коралга патрон итеп үзгәртеп кору, шома көпшәле ату коралының көүсәсен чабу нәтиҗәсендә кыскарту, нәтиҗәдә ул әйләнешкә тыелган була һ.б.), мондый үзгәрешнең нәтиҗәләренә бәйсез рәвештә зарарлау үзенчәлекләре саклана.

Сигнал, старт, төзелеш-монтаж пистолетлары һәм револьверлары, электрошок җайланмалары, хуҗалык-көнкүреш һәм җитештерү билгеләнешендәге әйберләр сыйфатында сертификацияләнгән предметлар, корал белән конструктив охшаш спорт снарядлары коралга карамыйлар.

Зарарлаучы элементы (снаряд, пуля, ядрә, картечь һәм б.ш.) булмаган һәм цельгә тидерү өчен билгеләнмәгән сигнал, яктырту, буш, төзелеш, газ, уку һәм башка патроннар сугыш кирәк-яракларына, шартлаткыч матдәләргә һәм шартлаткыч җайланмаларга керми.

Имитация-пиротехника һәм яктырту чаралары шартлаткыч матдәләргә һәм шартлаткыч җайланмаларга карамый.

2. Аларда сакланган (шул исәптән эчке эшләр органнарының тиешле рөхсәтеннән башка) коралны, сугыш кирәк-яракларын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлату җайланмаларын үз теләге белән тапшырган затларга, әгәр аларның гамәлләрендә башка җинаять составы булмаса, әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән күләмдә акчалата түләү бирелә.

3. Аңарда сакланган (шул исәптән эчке эшләр органнарының тиешле рөхсәтеннән башка) коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм шартлаткыч матдәләрне түләүле нигездә тапшыру теләген белдергән граждан Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы буйсынуындагы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының теләсә кайсы район дәрәҗәсендәге территориаль органына үз сайлавы буенча мөрәҗәгать итә. Бу вакытта мөрәҗәгатьнең конфиденциальлеге саклана.

4. Кәүсәсе киселгән күпшәле ирекле рәвештә тапшырылган утлы корал Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә контроль атып алынырга тиеш.

5. Акчалата түләү түбәндәге күләмдә бирелә:

сугыш утлы коралы, хезмәт утлы коралы өчен 15 000 сум;

кәүсәсе киселгән граждан утлы коралы өчен 10 000 сум;

шартлаткыч матдә өчен (шартлату матдәсен үз эченә алган) 8 000 сум, ләкин базар кыйммәтеннән арттырмыйча;

кабызгыч белән гранаталар, миналар, снарядлар өчен 5 000 сум;

шома кәүсәле граждан утлы коралы өчен 3000 сум;

кулдан ясалган яки яңадан ясалган (конструктив үзгәрешләргә дучар ителгән) утлы корал өчен 3000 сум;

пневматик (3 Дж дан артык), газ коралы һәм чикләнгән зарарлау белән утлы корал өчен 2000 сум;

шартлату чаралары (детонаторлар, шартлаткычлар, утүткәргеч чыбык һ.б.) өчен 500 сум;

утлы коралның төп өлешләре өчен 500 сум;

шартлаткыч матдәләр (тротил, пластид, аммонит, гексоген һәм сәнәгать җитештерүендәге башка) өчен 50 сум (1 грамм өчен), ләкин базар бәясеннән арттырмыйча;

кәүсәсе киселгән утлы коралга патрон өчен 30 сум (1 берәмлек өчен), әмма базар бәясеннән арттырмыйча;

шома күпшәле утлы коралга патрон өчен 20 сум (1 берәмлек өчен), әмма базар бәясеннән арттырмыйча.

Шартлаткыч җайланма өчен акчалата бүләк күләме андагы шартлаткыч матдәнең күләменә бәйле рәвештә билгеләнә.

Законсыз саклана торган корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр турында ышанычлы мәгълүмат биргән өчен түләү корал, сугыш кирәк-яраклары һәм шартлаткыч матдәләрнең тәгаен төренә әлеге пункт белән билгеләнгән сумманың 50 проценты күләмендә билгеләнә. Аерым очракларда түләү күләме арттырылырга мөмкин.

Теркәлгән коралны ирекле тапшырган өчен хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы бәяләмәсе нигезендә әлеге пунктта билгеләнгән сумманың 50 проценты күләмендә стимуллаштыручы акчалата бүләк түләнә ала.

6. Акчалата бүләк алу өчен зат гариза белән мөрәҗәгать итә һәм «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле

үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә яисә аның филиалына түбәндәге документларны тапшыра:

паспорт яки Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне раслаучы башка документ;

салым органында исәпкә кую турында таныклык;

Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органы яисә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органы тарафыннан бирелә торган корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр кабул итү турында квитанция;

акча күчерү өчен банк реквизитлары (субсидия һәм пенсия счетларыннан тыш);

шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен гариза.

7. Коралны, аның төп өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч матдәләр һәм шартлаткыч җайланмаларны ирекле биргән өчен түләүне гамәлгә ашыру турында карар яки түләүне гамәлгә ашырудан баш тарту турында карар һәм акчалата бүләк күләмен билгеләү хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы бәяләмәсе нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителә.

8. Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы бәяләмәсе «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесеннән яисә аның филиалларыннан кергән документлар нигезендә рәсмиләштерелә.

Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы эшенә Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең лицензия рөхсәт эше белгечләре җәлеп ителә (килешү буенча).

9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы кабул ителгән карар турында затка аны кабул иткән көннән соң 10 эш көне эчендә хәбәр итә.

10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы ай саен, 10 числога кадәр, түләү күләмен, паспорт мәгълүматларын, салым түләүченең идентификация номерын, банк реквизитларын күрсәтеп һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль координация органы бәяләмәләренең төп нөсхәләрен һәм әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен теркәп, реестрны төзи, аны түләүләрне гамәлгә ашыру өчен «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшыра.

11. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе гамәлдәге законнар нигезендә түләүләрне гамәлгә ашыру өлешендә салым агенты буларак чыга һәм физик затлар кеременә салымны санау, салым түләүчедән тотып калу һәм бюджетка күчерү бурычын үти.

Ел саен, финанс елы үткәннән соң, салым инспекциясенә 2 НДФЛ формасы буенча түләүләр турында мәгълүматлар бирә һәм түләү алучының язма гаризасы буенча аңа 2 НДФЛ формасы буенча белешмә бирә.